Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXII-5**

Балык Бистәсе штп. 24 июль 2018 ел

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча комиссия хакындагы Нигезләмәне раслау турында

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131-ФЗ номерлы, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы чаралар күрү турында”гы 273-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә һәм Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге “Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча комиссияләр турында”гы 821 номерлы Указын, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы “Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча комиссияләр турында”гы УП-569 номерлы Указын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча комиссия хакындагы теркәлүче Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 19 февралендәге “Татарстан Республикасының “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча комиссияләр турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы XXIX-1 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга

3.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 24 июлендәге
XXXII-5 номерлы карары белән
расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча комиссия турында Нигезләмә**

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Әлеге Нигезләмә белән 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы чаралар күрү турында”гы 273-ФЗ номерлы, 2007 елның 2 мартындагы”Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында”гы 25-ФЗ номерлы Федераль законнарга, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексына туры китереп һәм Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 1 июлендәге “Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча комиссияләр турында”гы 821 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 25 августындагы “Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча комиссияләр турында”гы УП-569 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасының “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә төзелгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында хезмәт (вазыйфа) тәртибенә карата куелган таләпләрне үтәүһәм мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча комиссияне (алга таба – комиссия) формалаштыру һәм аның эшчәнлек тәртибе билгеләнә.

1.2.Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституцион законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына, әлеге Нигезләмәгә һәм башка муниципаль норматив хокукый актларга таяна.

1.3.Комиссиянең төп бурычы булып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына (алга таба - җирле үзидарә органнары) булышлык итү тора:

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр (алга таба - муниципаль хезмәткәрләр), муниципаль вазыйфаларны алмаштыручы затлар тарафыннан чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр низагын булдырмау яки көйләү турындагы таләпләрне үтәү, шулай ук алар тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы чаралар күрү турында"гы 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән ( алга таба – хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләүгә таләпләр) бурычларны үтәүне тәэмин итү;

б) җирле үзидарә карамагындагы оешмалар (учреждениеләр) җитәкчеләре тарафыннан мәнфәгатьләр низагын булдырмау яки көйләү турындагы таләпләрне үтәүне тәэмин итү;

в)җирле үзидарә органнарында коррупцияне кисәтү чараларын тормышка ашыру.

1.4.Комиссия таләпләрне үтәү белән бәйле түбәндәге мәсьәләләрне карый:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштыручы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата куелган һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәвенә кагылышлы (алга таба - муниципаль хезмәт вазыйфалары);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны алмаштыручы затларга карата хезмәт тәртибенә карата куелган һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәвенә кагылышлы (алга таба - муниципаль вазыйфаларны алмаштыручы затлар) ;

җирле үзидарә карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчеләренә карата мәнфәгатьләр низагын көйләү турында.

1.5.Комиссия Татарстан Республикасының 2017 елның 19 июлендәге "Муниципаль вазыйфаны, җирле хакимият башлыгы вазыйфасын контракт нигезендә биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм контракт нигезендә муниципаль вазыйфалар, җирле хакимият башлыгы вазыйфаларын алмаштыручы затлар тарафыннан китерелгән мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында"гы 57-ЗРТ номерлы законы һәм Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 13 октябрендәге "Татарстан Республикасында коррупциягә каршы чаралар күрү буенча эшне координацияләү Комиссиясе турында"гы УП-986 номерлы Указы нигезендә эшләүче Татарстан Республикасында коррупциягә каршы чаралар күрү буенча эшне координацияләү Комиссиясе компетенциясенә кергән мәсьәләләрне карамый .

## 2. Комиссияне төзү тәртибе

2.1. Комиссия составы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы карары белән раслана.

Комиссия комиссия рәисеннән, комиссия рәисе урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.Карарлар кабул иткәндә комиссиянең барлык әгъзалары да тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе югында аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

2.2.Комиссия составына керәләр::

а) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы урынбасары (комиссия рәисе), муниципаль вазыйфаларны алмаштыручы затлар, җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең вазыйфаи заты, коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы зат (комиссия сәркатибе), муниципаль хезмәт һәм кадрлар мәсьәләләре буенча бүлекчәнең, юридик (хокук) бүлекчәнең , Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы тарафыннан билгеләнүче җирле үзидарә органарының башка бүлекчәләренең муниципаль хезмәткәрләре;

б) коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы ярдәмчесе;

в)фәнни оешмалар, һөнәри, югары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары вәкиле (вәкилләре).

2.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы комиссия составына кертү турында карар кабул итәргә мөмкин:

а)Татарстан Республикасының 2017 елның 27 апрелендәге “Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасы турында”гы 24-ЗРТ номерлы Законының 26 маддәсе нигезендә җирле үзидарә органы каршында төзелгән иҗтимагый совет вәкилен;

б) ветераннарның җирле үзидарә органында төзелгән иҗтимагый оешмасы, җирле үзидарә органында билгеләнгән тәртиптә эш алып баручы профсоюз оешмасы вәкилен.

2.4.Нигезләмәнең 2.2 пунктының “в” пунктчасында һәм 2.3 пунктында күрсәтелгән затлар комиссия составына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы запросы нигезендә билгеләнгән тәртиптә тиңдәшле рәвештә фәнни оешмалар, һөнәри, югары, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары, җирле үзидарә органы каршында төзелгән иҗтимагый совет, ветераннарның җирле үзидарә органында төзелгән иҗтимагый оешмасы, җирле үзидарә органында билгеләнгән тәртиптә эш алып баручы профсоюз оешмасы белән килештереп кертелә. Килештерү запрос алынганнан соң 10 көн срокта гамәлгә ашырыла.

2.5.Муниципаль хезмәт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны алмаштырмаучы комиссия әгъзаларының саны комиссия әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән ким булырга тиеш түгел.

2.6.Комиссия составы кабул ителә торган карарга йогынты ясардай мәнфәгатьләр низагы килеп чыгу ихтималы булмаслык итеп формалаштырыла.

2.7.Комиссия утырышларында фикер алышу хокукына ия тавыш белән катнашалар:

а) комиссия муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәү хакындагы мәсьәләне караганда хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесе;

б)муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштыручы башка муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль вазыйфаларны алмаштыручы затлар, муниципаль хезмәт һәм комиссия карый торган мәсьәләләр буенча аңлатма бирердәй белгечләр; дәүләт органнарының, башка җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары; кызыксынучы оешмалар вәкилләре; хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне

һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәү хакындагы мәсьәлә каралган муниципаль хезмәткәрнең вәкилләре, җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе муниципаль вазыйфасын алмаштыручы затлар, - һәр конкрет очракта аерым комиссия утырышына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча комиссия тарафыннан карала торган мәсьәлә аңа карата булган муниципаль хезмәткәр,муниципаль вазыйфаны алмаштыручы зат, җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе, яки комиссиянең теләсә кайсы әгъзасы биргән үтенеч нигезендә комиссия рәисе карары белән.

2.8.Комиссия әгъзалары гомуми санының өчтән икесеннән дә ким булмаган санда әгъзалар катнашканда комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала. Комиссия утырышын муниципаль хезмәт вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны алмаштыручы комиссия әгъ залары катнашында гына уздыру рөхсәт ителми.

2.9.Комиссия әгъзасында комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр низагына китерергә мөмкин булган туры яки читләтеп кызыксыну барлыкка килгәндә ул бу турыда утырыш башланганчы белдерергә бурычлы. Мондый очракта комиссиянең тиешле әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.

## 3.Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата һәм мәнфәгатьләр низагын көйләүгә куелган таләпләрне үтәүгә кагылышлы мәсьәләләрне карау тәртибе

3.1. Комиссия утырышын уздыруга нигез булып тора:

а) җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә үткәрелгән муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелгән мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын, һәм муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата булган таләпләрне үтәвен тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләрне раслаучы материалларны тәкъдим итү:

муниципаль хезмәткәр тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең муниципаль норматив хокукый актлар белән каралган тәртиптә тәкъдим ителергә тиешле керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яки тулы булмаган мәгълүматларны китерү;

муниципаль хезмәткәр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәмәве хакында;

б)җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затына, коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы кешегә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә кергән:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары яки Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирлек Советы карары белән расланган вазыйфалар исемлегенә кертелгән җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыручы гражданның

коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа алмаштырырга яисә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эш башкаруга ризалык бирүе турында, әгәр бу оешманың муниципаль идарә буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) йөкләмәләренә керсә, муниципаль хезмәттән чыгу көненнән ике ел узганчы җиткерелгән мөрәҗәгате;

муниципаль хезмәткәрнең объектив сәбәпләр аркасында үзенең иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны тапшыру мөмкин булмавы хакында гаризасы;

муниципаль хезмәткәрнең чит дәүләт законнарына туры китереп аның компетентлы органнары тарафыннан бирелгән күрсәтмә нигезендә бу ил территориясендә булган хисапларыннан (кертемнәреннән), чит ил банкларында саклanучы наличный акча средстволарыннан һәм кыйммәтле әйберләреннән һәм (яки) аның чит ил финанс инструментларыннан файдалануына салынган арест, тыю белән бәйле рәвештә, яки башка аның ихтыярына яки иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының ихтыярына бәйле булмаган хәлләр аркасында 2013 елның 7 маендагы "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында хисаплар ачу һәм хисаплар (кертемнәр) булдыруны, наличный акча средстволарын һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит илләрнең финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында"гы 79-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба -79-ФЗ номерлы Федераль закон ) таләпләрен үтәү мөмкин булмавы турында гаризасы;

муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи йөкләмәләрен башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуының барлыкка килүен хәбәр итүе;

в)җирле үзидарә органы җитәкчесенең яки комиссиянең теләсә кайсы әгъзасының муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәвен тәэмин итүенә яки җирле үзидарә органында коррупцияне кисәтү буенча чараларны тормышка ашыруга кагылышлы гариза бирүе;

г) җирле үзидарә органы җитәкчесенең 2012 елның 3 декабрендәге "Дәүләт вазыйфаларын алмаштыручы затларның чыгымнарының һәм башка затларның аларның керемнәренә туры килүенә контроль турында"гы 230-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - 230-ФЗ номерлы Федераль закон) 3 маддәсенең 1 өлешендә каралганча муниципаль хезмәткәр китергән мәгълүматларның дөрес булмавы яки тулы булмавы турында раслаучы тикшерү материалларын тәкъдим итүе;

д) 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы чаралар күрү турында"гы " 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсенең 4 өлеше һәм Россия Федерациясенең Хезмәт кодексының 64.1 маллəсенә туры китереп, җирле үзидарә органына коммерция яки коммерцияле булмаган оешмадан җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыручы граждан белән

эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтүгә) хезмәт яки гражданлык-хокукый шартнамә төзү турында, әгәр бу оешма белән муниципаль идарә итү буенча аның аерым функцияләре гражданның җирле үзидарә органында вазыйфаны алмаштыру вакытында үтәгән вазыйфаи (хезмәт) йөкләмәләренә кергән булып шундый шартта, әлеге гражданга элегрәк бу оешма белән хезмәт яки гражданлык-хокукый мөнәсәбәтләргә керү комиссия тарафыннан кире кагылган булса яки мондый гражданга коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа алмаштыруга яки коммерция яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында эшләр башкаруга ризалык бирү турындагы мәсьәлә каралмаган булса, белдерү хәбәре керү .

3.2. Комиссия җинаятьләр һәм административ хокук бозулар турындагы хәбәрләрне, шулай ук аноним мөрәҗәгатьләрне карамый, хезмәт дисциплинасын бозу фактлары буенча тикшерүләр уздырмый.

3.2.1.Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыручы гражданин тарафыннан җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затына, коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы кешегә бирелә. Мөрәҗәгатьтә гражданның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, аның туу датасы, яшәү урынының адресы, муниципаль хезмәттән чыкканнан соңгы ике ел эчендә алмаштырган вазыйфалары, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешманың исеме, кайда урнашканлыгы, нинди эшчәнлек белән шөгыльләнүе, муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштырган вакыттагы вазыйфаи (хезмәт) йөкләмәләре, коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмага карата муниципаль идарә итү буенча функцияләре, шартнамәнең төре (хезмәт яки гражданлык-хокукый), аның гамәлдә булу срогы, шартнамә буенча эшләр (хезмәт күрсәтүләр) башкарган өчен түләү суммасы күрсәтелә. Җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең вазыйфаи заты, коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы кеше тарафыннан мөрәҗәгать карала, аның йомгаклары буенча мөрәҗәгатьнең асылын күздә тотып, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы чаралар күрү турында”гы ” 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсе таләпләреннщн чыгып дәлилле нәтиҗә әзерләнә .

3.2.2. Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгать муниципаль хезмәттән китәргә планлаштыручы муниципаль хезмәткәр тарафыннан бирелергә мөмкин, һәм ул әлеге Нигезләмәгә туры китереп каралырга тиеш.

3.2.3.Нигезләмәнең 3.1 пункты “д” пунктчасында күрсәтелгән белдерү хәбәре җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең вазыйфаи заты, коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы кеше катнашындагы бүлек тарафыннан карала һәм ул җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштырган гражданның 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы чаралар күрү турында”гы ” 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсе таләпләрен үтәве турында дәлилле нәтиҗә әзерли.

3.2.4. Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасында күрсәтелгән белдерү хәбәре җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең вазыйфаи заты, коррупцион һәм башка

хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы кеше тарафыннан карала һәм алар белдерү хәбәрен карау йомгаклары буенча дәлилле нәтиҗә әзерләүне гамәлгә ашыралар.

3.2.5. Нигезләмәнең 3.1 пункты "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне яки 3.1 пунктының "б" пунктчасының бишенче абзацы һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән белдерү хәбәрләрен карау йомгаклары буенча дәлилле нәтиҗәләр әзерләгәндә комиссия мөрәҗәгать яки белдерү хәбәрен тәкъдим иткән муниципаль хезмәткәр белән әңгәмә үткәрергә, аннан язмача аңлатмалар алырга хокуклы, ә җирле үзидарә органының җитәкчесе яки аның урынбасары, бу эшкә махсус вәкаләтле буларак, тиешле тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар юлларга мөмкин. Мөрәҗәгать яки белдерү хәбәре, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки белдерү хәбәре кергән көннәреннән җиде эш көне дәвамында комиссия рәисенә тәкъдим ителә.Запрослар юллану очрагында мөрәҗәгать яки белдерү хәбәре, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки белдерү хәбәре кергән көннәрдән алып комиссия рәисенә 45 көн эчендә тәкъдим ителә. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән артыкка түгел.

3.2.6. Нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3 һәм 3.2.4 пунктларында каралган дәлилле нәтиҗәләрдә булырга тиеш:

а) Нигезләмәнең 3.1 пунктының"б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм белдерү хәбәрләрендә бәян ителгән мәгълүмат;

б) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынучы оешмалардан алынган мәгълүмат;

в) Нигезләмәнең 3.1 пунктының"б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм "д" пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгать һәм белдерү хәбәрләрен алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилле йомгак, тагын шулай ук Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3, 3.11.1 пунктларына туры китереп, карарларның берсен кабул итү өчен киңәшләр.

3.3. Комиссия рәисе аңа муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә комиссия утырышын үткәрүгә нигез булырдай мәгълүматлар кергәндә:

а) 10 көнлек срокта комиссия утырышы датасын билгели. Шуның өстенә комиссия утырышы датасы күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән Нигезләмәнең 3.3.1 һәм 3.3.2 пунктларында каралган очраклардан тыш 20 көннән соңга калып билгеләнә алмый.

б) комиссия тарафыннан хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне аның үтәве хакындагы мәсьәлә каралган муниципаль хезмәткәрне, аның вәкилен, комиссия утырышында катнашучы комиссия әгъзаларын һәм башка затларны җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затына, коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы кешегә кергән мәгълүматлар һәм аларны тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыра;

в) комиссия утырышына Нигезләмәнең 2.7 пунктының “б” пунктчасында күрсәтелгән затларны чакыру турындагы үтенечләрене карый, аларны канәгатьләндерү турында (канәгатьләндерүне кире кагу турында) һәм комиссия утырышы барышында өстәмә материалларны карау турында (карауны кире кагу турында) карар кабул итә.

3.3.1. Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән гаризаларны карау буенча комиссия утырышы керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматларны тапшыру өчен билгеләнгән срок чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча уздырыла.

3.3.2.Нигезләмәнең 3.1 пунктының “д” пунктчасында күрсәтелгән белдерү хәбәре комиссиянең чираттагы (пландагы) утырышында карала.

3.4.Комиссия утырышы, гадәттә, хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне аның үтәве хакындагы мәсьәлә муниципаль хезмәткәрнең яки җирле үзидарә органында муниципаль хезмәтне алмаштыручы гражданның үзләре катнашында үткәрелә. Муниципаль хезмәткәр яки гражданин комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында Нигезләмәнең 3.1 пунктының “б” пунктчасына туры китереп бирелә торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерү хәбәрендә күрсәтә.

3.4.1. Комиссия утырышлары муниципаль хезмәткәр яки гражданның катнашыннан башка үткәрелергә мөмкин очрак:

а) әгәр Нигезләмәнең 3.1 пунктының “б” пунктчасына туры китереп бирелә торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яки белдерү хәбәрендә муниципаль хезмәткәр яки гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтелмәсә;

б)әгәр комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте булган һәм тиешле рәвештә вакыты һәм үткәрелү урыны турында хәбәр алган муниципаль хезмәткәр яки граждан комиссия утырышына килмәсә.

3.5. Комиссия утырышында муниципаль хезмәткәрнең яки җирле үзидарә органында муниципаль хезмәтне алмаштыручы гражданның (аларның ризалыгы белән) һәм башка затларның аңлатмалары тыңланыла, әлеге утырышка чыгарылган мәсьәлә буенча асылда материаллар, шулай ук өстәмә материаллар карала.

3.6.Комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашучы затлар комиссия эше барышында мәгълүм булган мәгълүматларны читкә таратырга тиеш түгел.

3.7. Нигезләмәнең 3.1 пункты “а” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр тарафыннан муниципаль норматив хокукый актларга туры китереп керемнәре, чыгымнары, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында тапшырган мәгълүматларының дөреслеген һәм тулылыгын расларга;

б) муниципаль хезмәткәр тарафыннан муниципаль норматив хокукый актларга туры китереп тапшырган әлеге пунктның “а” пунктчасында аталган мәгълүматларның дөрес булмавын һәм (яки) тулы булмавын расларга.

3.8. Нигезләмәнең 3.1 пункты “а” пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәвен расларга;

б) муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәмәвен расларга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне бозуның һич тә ярамаганлыгына күрсәтү кирәклеген киңәш итә.

3.9. Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а)гражданга коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа алмаштырырга яисә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында, әгәр бу оешма белән муниципаль идарә буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) йөкләмәләренә кергән булса, эш башкаруга ризалык бирергә,

б) гражданга коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа алмаштырырга яисә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада гражданлык-хокукый шартнамә шартларында, әгәр бу оешма белән муниципаль идарә буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) йөкләмәләренә кергән булса, эш башкарырга ризалык бирмәскә һәм кире кагуны дәлилләргә.

3.10. Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр тарафыннан иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларның тапшырылмау сәбәбенең объектив һәм нигезле икәнлеген танырга;

б) муниципаль хезмәткәр тарафыннан иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларның тапшырылмау сәбәбенең нигезле булмавын танырга. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыру буенча чаралар күрергә киңәш итә.

в) муниципаль хезмәткәр тарафыннан иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматларның тапшырылмау сәбәбенең объектив түгеллеген һәм күрсәтелгән мәгълүматларны тапшырудан качарга тырышу ысулы булуын танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.10.1. Нигезләмәнең 3.1 пункты “г” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр тарафыннан 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 маддәсенең 1 өлешенә туры китереп бирелгән мәгълүматларның дөрес һәм тулы булуын танырга;

б) муниципаль хезмәткәр тарафыннан 230-ФЗ номерлы Федераль законның 3 маддәсенең 1 өлешенә туры китереп бирелгән мәгълүматларның дөрес булмавын һәм тулы түгеллеген танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә һәм (яки) чыгымнарга контроль булдыру нәтиҗәсендә алынган материалларны прокуратура органнарына һәм (яки) компетенцияләренә тиңдәшле рәвештә башка дәүләт органнарына юлларга киңәш итә.

3.10.2. Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының дүртенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы шартларның объектив һәм нигезле булуын танырга;

б) 79-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәүгә комачаулаучы шартларның объектив булмавын һәм нигезле түгеллеген танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.10.3. Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәр тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә мәнфәгатьләр низагы булмауны танырга;

б) муниципаль хезмәткәр тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә шәхси кызыксынуның мәнфәгатьләр низагына китерүен яки китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә һәм (яки) җирле үзидарә органы җитәкчесенә мәнфәгатьләр низагын көйләү яки аның килеп чыгуын булдырмау буенча чаралар күрергә киңәш итә.

в) муниципаль хезмәткәрнең мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәмәвен танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата конкрет җаваплылык чарасы күрергә киңәш итә.

3.11. Нигезләмәнең 3.1 пунктының “а”, “б”,”г”һәм “д” пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия аңа җирлек булганда Нигезләмәнең 3.7-3.10, 3.10.1-3.10.3 һәм 3.11.1 пунктларында каралганнан тыш башка карар кабул итәргә мөмкин. Мондый карарны кабул итүнең нигезе һәм сәбәпләре комиссиянең утырыш беркетмәсендә чагылыш табарга тиеш.

3.11.1. Нигезләмәнең 3.1 пункты “д” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыручы гражданга карата түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада аңа вазыйфа алмаштырырга яисә коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада

гражданлык-хокукый шартнамә шартларында, әгәр бу оешма белән муниципаль идарә буенча аерым функцияләре аның вазыйфаи (хезмәт) йөкләмәләренә кергән булса, эш башкаруга ризалык бирергә;

б) аның тарафыннан хезмәт килешүләре шартларында коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада вазыйфа алмаштырырга һәм (яки) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешмада эш башкару (хезмәт күрсәтүләр) 2008 елның 25 декабрендәге "Коррупциягә каршы чаралар күрү турында"гы " 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 маддәсе таләпләрен бозуын билгеләргә.Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә күрсәтелгән хәлләр турында прокуратура органнарын һәм хәбәр белдерүче оешмага хәбәр итәргә киңәш итә.

3.12. Нигезләмәнең 3.1 пункты "в" пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия тиешле карар кабул итә.

3.13.Комиссия карарларын үтәү өчен җирле үзидарә органының норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органы җитәкчесенең карарлар һәм йөкләмәләр проектлары әзерләнергә мөмкин, алар тиешле тәртиптә җирле үзидарә җитәкчесе каравына тапшырыла.

3.14. Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча комиссия карарлары яшерен тавыш бирү юлы белән (әгәр комиссия башка карар кабул итмәсә) утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

3.15.Комиссия карары утырышта катнашучы комиссия әгъзалары кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссия карарлары Нигезләмәнең 3.1 пункты "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителгән карарны исәпләмәгәндә җирле үзидарә органы җитәкчесе өчен киңәш бирү характерында була. 3.1 пункты "б" пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча кабул ителгән карар мәҗбүри характерда була.

3.16.Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

а)комиссия утырышының датасы, утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре;

б) комиссия утырышында карала торган хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәве турындагы мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасын күрсәтеп һәрбер мәсьәләнең формулировкасы;

в) муниципаль хезмәткәргә белдерелә торган дәгъвалар, алар нигезләнә торган материаллар;

г) муниципаль хезмәткәр һәм башка затларның белдерелә торган дәгъваларның асылы буенча аңлатмаларының эчтәлеге;

д)утырышта чыгыш ясаучы затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм аларның чыгышларын кыскача бәян итү;

е) комиссия утырышын уздыруга нигез булып торган мәгълүматлы чыганак, мәгълүматның җирле үзидарә органына керү датасы;

ж) башка мәгълүматлар;

з) тавыш бирү нәтиҗәләре;

и) карар һәм аны кабул итүне дәлилләү.

3.17.Комиссиянең карары белән риза булмаган комиссия әгъзасы үз фикерен комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри теркәлергә тиешле буларак язмача бәян итәргә хаклы һәм аның белән муниципаль хезмәткәр таныштырылырга тиеш.

3.18. Комиссия утырышы беркетмәсенең копияләре утырыш көненнән соңгы җиде көн эчендә җирле үзидарә органы җитәкчесенә җибәрелә, тулысы белән яки аннан өземтәләр рәвешендә - муниципаль хезмәткәргә, шулай ук комиссия карары буенча – башка кызыксынучы затларга.

3.19. Җирле үзидарә органы җитәкчесе комиссия утырышы беркетмәсен карап тикшерергә бурычлы һәм үзенең компетенциясе чикләрендә андагы киңәшләрне муниципаль хезмәткәргә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган , шулай ук коррупциягә каршы чаралар күрүне оештыруның башка мәсьәләләре буенча җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул иткәндә исәпкә алырга хокуклы. Комиссия киңәшләрен карау һәм кабул ителгән карар турында җирле үзидарә органы җитәкчесе язмача формада комиссия утырышы беркетмәсен алган көннән соң бер ай срокта комиссиягә белдерү хәбәре җибәрә. Җирле үзидарә органы җитәкчесенең карары комиссиянең якындагы утырышында игълан ителә һәм фикер алышмыйча гына игътибарга алына.

3.20. Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең гамәлләрендә (гамәл кылмавында) дисциплинар гаеп эш билгеләре раслану очрагында ул турыда муниципаль хезмәткәргә карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чаралары куллану турындагы мәсьәләне хәл итү өчен җирле үзидарә органы җитәкчесенә хәбәр ителә

3.21.Комиссия тарафыннан муниципаль хезмәткәрнең административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре булган гамәл кылу (гамәл кылмау) факты расланганда, комиссия рәисе гамәл кылу (гамәл кылмау) турындагы хәбәрне һәм андый фактны раслаучы документларны өч көн срок эчендә, зарур булганда, кичекмәстән, хокук саклау органнарына тапшырырга бурычлы.

3.22.Комиссия утырышы беркетмәсенең копиясе яки аннан өземтә хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәве хакында мәсьәлә каралган муниципаль хезмәткәрнең шәхси делосына теркәлә

3.22.1. Комиссия сәркатибе имзасы һәм җирле үзидарә органы мөһере белән расланган комиссия карарыннан өземтә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштырган Нигезләмәнең 3.1 пункты “б” пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мәсьәлә каралган гражданга кул куйдырып үзенә тапшырыла яки заказлы хат аша белдерү хәбәре белән аның мөрәҗәгатьтә күрсәткән адресы буенча тиндәшле комиссия утырышы үткәрелгән көннән соң килүче беренче көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

3.23.Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник һәм документацион тәэмин итү, шулай ук комиссия әгъзаларына көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итү, комиссия әгъзаларын комиссия утырышында фикер алышу өчен тәкъдим ителәчәк материаллар белән таныштыру җирле үзидарә органының коррупцион һәм башка хокук бозуларны

кисәтү буенча кадрлар хезмәте бүлеге тарафыннан яки җирле үзидарә органы кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затлары, коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча җаваплы кешеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 4 Муниципаль вазыйфаларны алмаштыручы затларның вазыйфаи тәртибенә карата һәм мәнфәгатьләр низагын көйләүгә куелган таләпләрне үтәвенә кагылышлы мәсьәләләрне Комиссия тарафыннан карау тәртибе

4.1Комиссия утырышларын үткәрү өчен нигез булып тора:

а)муниципаль вазыйфаны алмаштыручы зат тарафыннан вазыйфаи тәртипкә куелган таләпләрне бозу турында закон тәртибендә кергән материаллар нигезендә кабул ителгән комиссия рәисе карары;

б)вазыйфаи йөкләмәләрне үтәгәндә мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү , шулай ук дәлилле нәтиҗә һәм башка материаллар турында комиссиягә кергән белдерү хәбәре.

4.2.Комиссия тарафыннан Нигезләмәнең 4.1 пунктының “б” пунктчасында күрсәтелгән белдерү хәбәрен алдан карау гамәлгә ашырыла һәм аны карау йомгаклары буенча дәлилле нәтиҗә әзерләнә.

4.2.1.Нигезләмәнең 4.2 пунктында каралган дәлилле нәтиҗәне әзерләгәндә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы йөкләмәсе буенча комиссия тиешле тәртиптә Нигезләмәнең 4.1 пунктына туры китереп белдерү хәбәрен тапшырган заттан кирәкле аңлатмаларны алырга хаклы, ә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы тиешле тәртиптә федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар юлларга мөмкин.

Белдерү хәбәре, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар белдерү хәбәре кергән көннән соң җиде эш көне дәвамында комиссия рәисенә тапшырыла.

Запрослар юллау очрагында белдерү хәбәре, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар белдерү хәбәре кергән көннән соң 45 эш көне дәвамында комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, тик 30 көннән артыкка түгел.

4.3.Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне тикшерүне комиссиянең алдан карау утырышының үткәрелү датасы һәм урыны комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

4.4.Комиссия сәркатибе комиссия утырышына чыгарылучы мәсьәләләрне карауга әзерлекне тәэмин итә, шулай ук комиссия әгъзаларына һәм муниципаль вазыйфаны алмаштыручы затка комиссиянең утырыш көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, датасы, вакыты утырышны үткәрү урыны турында утырыш көненә кадәр җиде эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр бирүне оештыра.

4.5.Әгәр комиссия утырышында вазыйфаи тәртипкә карата куелган һәм (яки) мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрне үтәү хакында мәсьәлә комиссия әгъзаларының берсенә карата каралса, комиссиянең әлеге әгъзасы,

Нигезләмәнең 4.9, 4.10 пунктларында каралганча, карар кабул иткәндә тавыш хокукына ия булмый.

4.6.Комиссия утырышы, гадәттә, Нигезләмәнең 4.1 пунктына туры китереп белдерү хәбәре тапшырган зат катнашында үткәрелә. Белдерү хәбәрен тапшыручы зат үзенең комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте барлыгын белдерү хәбәрендә күрсәтә.

4.6.1. Комиссия утырышлары Нигезләмәнең 4.1 пунктына туры китереп белдерү хәбәре тапшырган заттан башка түбәндәге очракларда үткәрелергә мөмкин:

а) әгәр белдерү хәбәрендә белдерү хәбәрен тапшыручы зат үзенең комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте барлыгын күрсәтмәсә;

б) әгәр комиссия утырышында шәхсән катнашуга нияте булган һәм тиешле рәвештә утырыш үткәрелү вакыты һәм урыны турында хәбәр алган белдерү хәбәрен тапшыручы зат комиссия утырышына килмәсә.

4.7.Комиссия утырышында комиссия рәисе билгеләгән тәртиптә муниципаль вазыйфаны алмаштыручы затның аңлатмалары тыңланыла һәм утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә кагылышлы материаллар карала.Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының һәм муниципаль вазыйфаны алмаштыручы зат үтенече буенча башка затлар тыңланылырга һәм алар тәкъдим иткән материаллар каралырга мөмкин.

4.8. Комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашучы затлар комиссия эше барышында мәгълүм булган мәгълүматларны читкә таратырга хаклы түгел.

4.9.Нигезләмәнең 4.1 пункты “а” пунктчасына туры китереп материалларны карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) каралган очракта муниципаль вазыйфаны алмаштыручы зат тарафыннан вазыйфаи тәртипкә куелган таләпләрне бозу билгеләренең булмавын расларга;

б) каралган очракта муниципаль вазыйфаны алмаштыручы зат тарафыннан вазыйфаи тәртипкә куелган таләпләрне бозу билгеләренең булуын расларга;

4.10. Нигезләмәнең 4.1 пункты “б” пунктчасына туры китереп белдерү хәбәрен карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) белдерү хәбәрен тапшырган зат тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә мәнфәгатьләр низагының булмауны танырга;

б) белдерү хәбәрен тапшырган зат тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә шәхси кызыксынуның мәнфәгатьләр низагына китерүен яки китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта комиссия белдерү хәбәрен тапшырган затка мәнфәгатьләр низагын булдырмау яки көйләү буенча чаралар күрергә киңәш итә.

в) белдерү хәбәрен тапшырган зат тарафыннан мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрнең үтәлмәвен танырга. Кабул ителгән карар турында комиссия рәисе яисә комиссия сәркатибе җирле үзидарә органының вазыйфаи затына яки Россия Федерациясе законнарында каралганча юридик җаваплылык чараларын кулланырга вәкаләтле оешмага белдерә.

4.11. Комиссия тарафыннан муниципаль вазыйфаны алмаштыручы затның административ хокукны бозу яки җинаять составы билгеләре булган гамәл кылу

(гамәл кылмау) факты расланганда, комиссия сәркатибе комиссия рәисе йөкләмәсе буенча күрсәтелгән гамәл кылу (гамәл кылмау) турындагы хәбәрне һәм андый фактны раслаучы документларны өч көн срок эчендә, зарур булганда, кичекмәстән, хокук саклау органнарына юллый.

4.12. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән коллегиаль кабул ителә. Тавышлар тигезлегендә комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

4.13. Комиссия карары комиссия рәисе һәм сәркатибенең имзалары куелган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

4.13.1.Нигезләмәнең 4.1 пунктының “б” пунктчасында каралган белдерү хәбәрендә аны тапшырган затның комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтү булмаса, комиссия рәисе карары белән Нигезләмәнең 4.1 пунктының “б” пунктчасында күрсәтелгән мәсьәлә буенча тавыш бирү комиссия әгъзаларына сорашу кәгазьләре, шулай ук башка материалларны җибәрү юлы белән читтән торып үткәрелергә мөмкин.

Сорашу кәгазен тутырганда комиссия әгъзасы комиссия тәкъдим иткән карарга карата аны яклап яки каршы тавыш биреп үзенең бер генә мәгънәле фикерен белдерергә тиеш. Комиссия әгъзасы кул куйган сорашу кәгазе алынган көннән соң өч көннән дә артык соңармыйча комиссиягә җибәрелә.

Комиссиянең читтән торып тавыш бирү нәтиҗәсендә кабул ителгән карары Нигезләмәнең 4.14 пунктындагы таләпләргә туры китереп беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм беркетмәгә кул куелганнан соң җиде эш көне эчендә комиссия әгъзаларына һәм кызыксынучы затларга җибәрелә.

4.14.Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

а) комиссия утырышының датасы, утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б)комиссия утырышында каралган мәсъәләләрнең әлеге мәсьәлә карала торган муниципаль вазыйфаны алмаштыручы вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелеп һәрберсенең формулировкасы:

в) комиссия утырышын уздыру өчен нигез булган хәбәр чыганагы һәм хәбәрнең керү датасы;

г) муниципаль вазыйфаны алмаштыручы затның һәм башка затларның карала торган мәсьәләләрнең асылы буенча аңлатмаларының эчтәлеге;

д)утырышта чыгыш ясаучы затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм аларның чыгышларын кыскача бәян итү;

е) башка мәгълүматлар;

ж) тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) карар һәм аны кабул итүне дәлилләү.

4.15. .Комиссиянең карары белән риза булмаган комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри теркәлергә тиешле булганлыктан язмача бәян итәргә хаклы.

4.16. Комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтә комиссия утырышы беркетмәсенә кул куелган көннән соң биш эш көне эчендә мәсьәлә каралган

муниципаль вазыйфаны алмаштыручы затка, шулай ук вазыйфаи затка (җирле үзидарә органына), аны билгеләүгә ( сайлауга, раслауга) вәкаләтле кешегә җибәрелә

4.17.Комиссия карарына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

**5. Комиссия тарафыннан**
**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганнда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе турындагы хәбәрен карау тәртибе**

5.1.Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез булып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең вазыйфаи йөкләмәләрне башкарганда мәнфәгатьләр низагына китерүче яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе турындагы хәбәренең (алга таба – белдерү хәбәре), һәм дә шулай ук дәлилле нәтиҗә һәм башка материалларның комиссиягә килүе тора.

5.2.Комиссия тарафыннан Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән белдерү хәбәрен алдан карау гамәлгә ашырыла, һәм карау йомгаклары буенча дәлилле нәтиҗә әзерләнә.

5.3.Нигезләмәнең 5.2 пунктында каралган дәлилле нәтиҗәне әзерләгәндә комиссия билгеләнгән тәртиптә Нигезләмәнең 5.1 пунктына туры китереп белдерү хәбәрен җиткергән затлардан кирәкле аңлатмаларны алырга, ә оешманы (учреждениене) гамәлгә куючы җирле үзидарә органы җитәкчесе яки аның моңа вәкаләте булган урынбасары тиешле тәртиптә федераль дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы һәм башка Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга запрослар җибәрергә мөмкин.

Белдерү хәбәре, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар гариза яки белдерү хәбәре кергән көннән соң җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла.

Запрослар җибәрү очрагында белдерү хәбәре, шулай ук нәтиҗә һәм башка материаллар гариза яки белдерү хәбәре кергән көннән соңгы 45 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, тик 30 көннән артыкка түгел.

5.4. Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне тикшерүне комиссиянең алдан карау утырышының үткәрелү датасы һәм урыны комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

5.5. Комиссия сәркатибе комиссия утырышына чыгарылучы мәсьәләләрне карауга әзерлекне тәэмин итә, шулай ук комиссия әгъзаларына һәм Нигезләмәнең 5.1,5.3 пунктларында күрсәтелгән затларга комиссиянең утырыш көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр, датасы, вакыты, утырышны үткәрү урыны турында утырыш көненә кадәр җиде эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр бирүне оештыра.

5.6.Комиссия утырышы, гадәттә, Нигезләмәнең 5.1 пунктына туры китереп белдерү хәбәрен тапшырган зат катнашында уздырыла. Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында белдерү хәбәрен тапшырган зат белдерү хәбәрендә күрсәтә.

5.6.1. Комиссия утырышлары Нигезләмәнең 5.1 пунктына туры китереп белдерү хәбәрен тапшырган заттан башка түбәндәге очракларда уздырылырга мөмкин :

а)әгәр белдерү хәбәрендә белдерү хәбәрен тапшыручы зат үзенең комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте барлыгын күрсәтмәсә;

б) әгәр комиссия утырышында шәхсән катнашуга нияте булган һәм тиешле рәвештә утырыш үткәрелү вакыты һәм урыны турында хәбәр алган белдерү хәбәрен тапшыручы зат комиссия утырышына килмәсә.

5.7. Комиссия утырышында комиссия рәисе билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең аңлатмалары тыңланыла һәм утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләргә кагылышлы материаллар карала. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең үтенече буенча башка затлар тыңланылырга һәм алар тәкъдим иткән материаллар каралырга мөмкин.

5.8. Комиссия әгъзалары һәм утырышта катнашучы затлар комиссия эше барышында мәгълүм булган мәгълүматларны читкә таратырга хаклы түгел.

5.9. Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән белдерү хәбәрен карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә мөмкин:

а) белдерү хәбәрен тапшырган зат тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә мәнфәгатьләр низагының булмавын танырга;

б) белдерү хәбәрен тапшырган зат тарафыннан вазыйфаи йөкләмәләрен үтәгәндә шәхси кызыксыну мәнфәгатьләр низагына китерә яки китерергә мөмкин булуын танырга. Бу очракта комиссия белдерү хәбәрен тапшырган затка мәнфәгатьләр низагын булдырмау яки көйләү буенча чаралар күрергә киңәш итә.

в) белдерү хәбәрен тапшырган зат тарафыннан мәнфәгатьләр низагын көйләү турындагы таләпләрнең үтәлмәвен танырга. Бу очракта Комиссия киңәш итә:

эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә карата конкрет җаваплылык чарасы кулланырга;

белдерү хәбәрен тапшырган затка мәнфәгатьләр низагын көйләү буенча чаралар күрергә.

5.10. Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең административ хокукны бозу яки җинаять составы билгеләре булган гамәл кылу (гамәл кылмау) факты расланганда, комиссия сәркатибе комиссия рәисе йөкләмәсе буенча күрсәтелгән гамәл кылу (гамәл кылмау) турындагы хәбәрне һәм андый фактны раслаучы документларны өч көн срок эчендә, зарур булганда, кичекмәстән, хокук саклау органнарына юллый.

5.11. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән коллегиаль кабул ителә. Тавышлар тигезлегендә комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

5.12. Комиссия карары комиссия рәисе һәм сәркатибенең имзалары куелган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.13. Нигезләмәнең 5.1 пунктында каралган белдерү хәбәрендә аны тапшырган затның комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында күрсәтү булмаса, комиссия рәисе карары белән Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча тавыш бирү комиссия әгъзаларына сорашу кәгазьләре, шулай ук башка материалларны җибәрү юлы белән читтән торып үткәрелергә мөмкин.

Сорашу кәгазен тутырганда комиссия әгъзасы комиссия тәкъдим иткән карарга карата аны яклап яки каршы тавыш биреп үзенең бер генә мәгънәле фикерен белдерергә тиеш. Комиссия әгъзасы кул куйган сорашу кәгазе алынган көннән соң өч көннән дә артык соңармыйча комиссиягә җибәрелә.

Комиссиянең читтән торып тавыш бирү нәтиҗәсендә кабул ителгән карары Нигезләмәнең 4.14 пунктындагы таләпләргә туры китереп беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм беркетмәгә кул куелганнан соң җиде эш көне эчендә комиссия әгъзаларына һәм кызыксынучы затларга җибәрелә.

5.14. Комиссия утырышы беркетмәсендә күрсәтелә:

а) комиссия утырышының датасы, утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының һәм башка затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме;

б)комиссия утырышында каралган мәсъәләләрнең әлеге мәсьәлә аңа карата карала торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелеп һәрберсенең формулировкасы:

в) комиссия утырышын уздыру өчен нигез булган хәбәр чыганагы һәм хәбәрнең керү датасы;

г) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенең һәм башка затларның карала торган мәсьәләләрнең асылы буенча аңлатмаларының эчтәлеге;

д)утырышта чыгыш ясаучы затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм аларның чыгышларын кыскача бәян итү;

е) башка мәгълүматлар;

ж) тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) комиссиянең карары һәм аны кабул итүне дәлилләү.

5.15. Комиссиянең карары белән риза булмаган комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри теркәлергә тиешле булганлыктан язмача бәян итәргә хаклы.

5.16. Комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтә комиссия утырышы беркетмәсенә кул куелган көннән соң биш эш көне эчендә мәсьәлә аңа карата каралган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесенә, шулай ук оешманы (учреждениене) гамәлгә куйган җирле үзидарә органына җибәрелә

5.17.Комиссия карарына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.